Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXX-1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге XI-1 номерлы, 2017 елның 24 июлендәге XX-1 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсендәге 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә, әлеге карарның 5 пункты белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән гайре.

5. Әлеге карарга кушымтаның 1 пунктындагы “в” пунктчасы, 11 пунктындагы “а” пунктчасының унҗиденче абзацы 2018 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Кушымтаның 1 пунктындагы “а” пунктчасы, 3 пунктның “а” пунктчасы, 11 пунктның “а” пунктчасындагы ундүртенче һәм унбишенче абзацлары, 11 пунктның “в” пунктчасындагы беренче һәм икенче абзацлары 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Әлеге карарга кушымтаның 1 пунктындагы “б” пунктчасының беренче һәм икенче абзацлары, 11 пунктындагы “а” пунктчасының уникенче һәм унөченче абзацлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советы рәисе урынбасары И.Г. Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 12 апрелендәге
XXX-1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлешендә:

а) 5 пунктта "район чикләрендә торак пунктларыннан читтәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышы өчен"сүзләренә ",юл хәрәкәте оешмасы" сүзләрен өстәргә;

б) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16) район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерып туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;";

в) 30 пунктны "(волонтерлык)" сүзе белән тулыландырырга;

г) 37 пунктында "районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәре," сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7маддәнең 1 өлешендә:

а) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту;";

б) түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктны өстәргә:

"12) инвалидларның физик культурасын һәм спортын, физик мөмкинлекләре чикләнгән затларның адаптив физик культурасын һәм адаптив спортын үстерүгә ярдәм күрсәтү.";

3) 8 маддәнең 1 өлешендә:

а) 2 пунктка "авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен,"сүзләреннән соң "юл хәрәкәтен оештыру" сүзләрен өстәргә;

б) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарын, аеруча саклanudагы табигать территорияләреннән файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу эшләрен оештыру;”;

4) 13 маддәнең 1 өлешендәге 4 пунктына “җәмәгатьчелек фикер алышулары” сүзләрен өстәргә;

5) 17 маддәдә:

а) исемне (аталышны) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17 маддә. Гавами тыңлаулар, җәмәгатьчелек фикер алышулары”;

б) 3 өлештә:

түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктын өстәргә:

“2.1) районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;”;

3 өлешнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 10 өлештә “Җәмәгатьчелек тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе”сүзләрен “Әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе,” сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 12 өлешне өстәргә:

“12. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәтнамә бирү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары буенча, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән бер төрен мондый кулланылышта булган башка төргә үзгәртү сораулары буенча җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре расланмаган очракта җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, район Уставы һәм район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.”;

6) 27 маддәнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Әлеге Уставның 26 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә район составына керүче авыл җирлекләре башлыкларыннан һәм әлеге җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан торган район Советы депутаты вәкаләтләре район составына керүче авыл җирлеге башлыгы вазыйфасына керешкәннән соң яки әлеге җирлекнең вәкиллекле органы депутаты район Советы депутаты итеп билгеләнгән көннән башлана һәм яңа сайланган авыл җирлеге башлыгы вазыйфасына керешкән көннән яисә әлеге җирлектән район Советы составына депутат сайлау турындагы карар үз көченә кергән көннән туктатыла.”;

7) 28 маддәнең 5 өлешендә “район Советы” сүзләрен “район Башкарма комитеты “ сүзләренә алмаштырырга;

8) 30 маддәнең 1 өлешендә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) районның социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;”;

б) түбәндәге эчтәлектәге 6.1-6.4 пунктларын өстәргә:

“6.1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең приоритетлары һәм максатлары белән килештерелгән районның социаль-икътисадый үсеше һәм муниципаль идарәнең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

6.2) җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын карау, раслау (хуплау);

6.3) җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыруга контроль;

6.4) стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләр;”;

в) түбәндәге эчтәлекле 33.1 пунктын өстәргә:

“33.1) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.”;

9) 41 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Әгәр Татарстан Республикасы Президентының район Башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турындагы хокукый акты яисә отставкага җибәрү турында район Советы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта район Башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга суд тәртибендә шикаять бирә, суд карары законлы көченә кергәнче район Советы үз составыннан Башлык сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.”;

10) 43 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 3 нче өлешне өстәргә:

“3. Коррупцион хокук бозу кылган өчен ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү (вазыйфадан азат итү) рәвешендәге җәза чарасын муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата куллану турында мәгълүматлар “Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендә каралган ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына әлеге зат тиешле вазыйфаны биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан кертелә.”;

11) 46 маддәдә:

а) 1 өлештә:

1 пунктта:

сигезенче – унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-районның социаль-икътисади үсеше стратегиясе проектын эшләүне тәэмин итә;

-район бюджетының үтәлешен оештыра, районның социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыра.;

- районның социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыру турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;

- икътисад һәм социаль өлкә торышын сыйфатлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә бирүне оештыра;”;

түбәндәге эчтәлектәге ундүртенче-уналтынчы абзацларны өстәргә:

“-җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын эшләүне һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыра;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыру мониторингын гамәлгә ашыра;

- стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;”;

3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“-район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерып туплауны), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша;”;

4 пунктта:

икенче абзацка “район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышы өчен” сүзләрен соң “,юл хәрәкәте оешмасы” сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта “муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәре,” сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның унынчы абзацына “(волонтерлык)” сүзен өстәргә;

б) 2 өлештә:

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту;”;

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктны өстәргә:

“12) инвалидларның физик культурасын һәм спортын, физик мөмкинлекләре чикләнгән затларның адаптив физик культурасын һәм адаптив спортын үстерүгә ярдәм күрсәтү.”;

в) 3 өлештә:

а) 2 пунктка “авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен,”сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру” сүзләрен өстәргә;

б) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарын, аеруча саклanудагы табигать территорияләреннән файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу эшләрен оештыру;”;

12) 50 маддәнең 1 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) район Советы каравына районның социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын һәм аны тормышка ашыру турында хисап тәкъдим итә;";

13) 54 маддәнең 6 өлешендәге 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14) муниципаль программаларны тормышка ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен контрольдә тоту;";

14) 74 маддәдә:

а) 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

"Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын районда таратыла торган вакытлы матбугатта бастырып чыгару санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәрле басмадан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның рәсми челтәр басмасында тулы тексты басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, күләмле график һәм таблица кушымталары басма матбугатта китерелмәскә мөмкин.";

б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлешне өстәргә:

"4.1. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән һәр килешүдә аның реквизитлары булырга тиеш: аталышы, аңа кул кую датасы, килешүгә кул куйган вазыйфаи затларның аталышлары";

в) түбәндәге эчтәлеклтәге 5.1 өлешне өстәргә:

"5.1. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә 7 көн эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.";

в) түбәндәге эчтәлектәге 8.1 өлешне өстәргә::

"8.1. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең реквизитлары күрсәтелә.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырып чыгару түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

- җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру (бастырып чыгару): http://pravo.tatarstan.ru;

- җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын районның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган гаммәви мәгълүмат чараларында яки район территориясендә таратыла торган һәм район Советы карары белән билгеләнгән бүтән гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын бастырганда, бүтән гаммәви мәгълүмат чараларында әлеге басманың рәсми бастырып чыгарылуы турында билге булырга тиеш.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү текстын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталындагы рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча урнаштыру ярдәмендә гамәлгә ашырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru .

15) 81 маддәдә:

а) 6 өлешендә:

өченче абзацта “сәясәтнең һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре” сүзләрен “,Россия Федерациясенең салым һәм таможня-тариф сәясәте (Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре)” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 12 өлешнең икенче абзацында “ һәм районның салым сәясәте” сүзләрен “,Россия Федерациясенең салым һәм таможня-тариф сәясәте (Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре)” сүзләренә алмаштырырга.